КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 декабрь г.Казань № 1328

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетларыннан субвенцияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 20 март, 210 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетларына субвенцияләр бирү тәртибенә 1 нче кушымтага үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетларына субвенцияләр бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 20 март, 210 нчы карары белән (Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 23 сентябрь, 908 нче карары белән расланган үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетларына субвенцияләр бирү тәртибенә, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетларына субвенцияләр бирү тәртибенә 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 30 декабрь, 1328 нче
карары редакциясендә)

Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның
аерым категорияләренә җәмәгать транспорты хезмәтләре күрсәтүгә
бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы муниципаль районындагы һәм
шәһәр округындагы транспорт оешмаларына алынып бетмәгән керемнәрен
компенсацияләү күләмен исәпләү
методикасы

1. Бу Методика Татарстан Республикасы территориясендә транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет һәм балаларга транспортта йөрү өчен бердәм айлык социаль билет (алга таба шул ук эзлеклелектә – транспортта йөрү билеты, балаларга транспортта йөрү билеты) буенча гражданнарның аерым категорияләренә җәмәгать транспорты хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы муниципаль районындагы һәм шәһәр округындагы (алга таба – муниципаль берәмлек) транспорт оешмаларына алынып бетмәгән керемнәрен компенсацияләү күләмен билгеләү өчен эшләнгән.

2. Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә транспортта йөрү билеты, балаларга транспортта йөрү билеты буенча җәмәгать транспорты хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә, муниципаль берәмлектәге транспорт оешмаларына алынып бетмәгән керемнәрен компенсацияләүнең гомуми күләме ($С_{общ}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С_{общ} = SUM\ С_i ,$$

монда $С_i$ – i транспорт оешмасына алынып бетмәгән керемнәре өчен бирелә торган компенсацияләр күләме.

3. Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә транспортта йөрү билеты, балаларга транспортта йөрү билеты

буенча җәмәгать транспорты хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә, i транспорт оешмасына алынып бетмәгән керемнәре өчен бирелә торган компенсацияләр күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$C_i = (SUM(T_{горji} \times П_{регjit} + T_{прi} \times P_{регit}) + SUM(N_{горji} \times П_{нерегjit} + N_{прi} \times P_{нерегit})) - B_{оргit},$$

монда:

j – i транспорт оешмасында транспорт төрләре (автобус, троллейбус, трамвай, метрополитен);

t – i транспорт оешмаларына хезмәт күрсәтүче автоматлаштырылган система операторы (алга таба – t оператор);

$T_{горji}$ – муниципаль берәмлектә шәһәр элемтәсендә җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырганда, транспорт төренә карамыйча, календарь айда билгеләнгән бер сан күләмендә транспортта йөрү хокукы бирә һәм озак вакыт файдалана торган билетлар белән транспортта йөрүгә түләү өчен түбәндәгеләр тарафыннан билгеләнә торган иң чик максималь тариф:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан – метрополитенда пассажирлар йөртү өлешендә;

Татарстан Республикасының тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимият органы тарафыннан – автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән пассажирлар йөртү өлешендә;

$П_{регjit}$ – хисап ае өчен t оператор мәгълүматлары буенча муниципаль берәмлектә шәһәр элемтәсендә җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырганда j транспорт төрендә i транспорт оешмасының транспортта йөрү билетлары һәм балаларга транспортта йөрү билетлары буенча юл йөрүләре (транзакцияләре) саны;

$T_{прi}$ – муниципаль берәмлектә бер пассажир-километр өчен шәһәр яны элемтәсендә җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багажлар ташу маршрутлары буенча автомобиль транспорты белән пассажирлар йөртү өчен Татарстан Республикасының тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән иң чик максималь тариф;

$P_{регit}$ – хисап ае өчен t оператор мәгълүматлары буенча муниципаль берәмлектә шәһәр яны элемтәсендә җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багажлар ташу маршрутларында i транспорт оешмасының автомобиль транспорты белән транспортта йөрү билетлары һәм балаларга транспортта йөрү билетлары буенча башкарылган пассажир-километр саны;

$N_{горji}$ – муниципаль берәмлектә шәһәр элемтәсендә җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларында j транспорт төрендә транспортта йөрү билеты һәм балаларга транспортта йөрү билеты буенча бер тапкыр транспортта йөрүнең (транзакциянең) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән кыйммәте;

$П_{нерегjit}$ – хисап ае өчен t оператор мәгълүматлары буенча муниципаль берәмлектә i транспорт оешмасының шәһәр элемтәсендә җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары буенча j транспорт төрендә транспортта йөрү билетлары һәм балаларга транспортта йөрү билетлары буенча юл йөрү (транзакцияләр) саны;

$N_{прi}$ – муниципаль берәмлектә шәһәр яны элемтәсендә җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларында автомобиль транспорты белән транспортта йөрү билеты һәм балаларга транспортта йөрү билеты буенча бер бер пассажир-километрның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән кыйммәте;

$P_{нерегit}$ – хисап ае өчен t оператор мәгълүматлары буенча муниципаль берәмлектә i транспорт оешмасының шәһәр яны элемтәсендә җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларында автомобиль транспорты белән транспортта йөрү билетлары һәм балаларга транспортта йөрү билетлары буенча башкарылган пассажир-километр саны;

$B_{оргit}$ – хисап ае өчен t оператор мәгълүматлары буенча муниципаль берәмлектә i транспорт оешмасының даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларында шәһәр һәм шәһәр яны элемтәсендә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә транспортта йөрү билетларына һәм балаларга транспортта йөрү билетларына акча салудан еллык табышының күләме, ул түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$B_{оргit} = (Ц_в \times P_{вt} + Ц_д \times P_{дt}) \times Д_{it},$$

монда:

$Ц_в$ – транспортта йөрү билетына акча салу өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән кыйммәте;

$P_{вt}$ – хисап ае өчен t оператор мәгълүматлары буенча муниципаль берәмлекләрдә акча салынган транспортта йөрү билетлары саны;

$Ц_д$ – балаларга транспортта йөрү билетына акча салу өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән кыйммәте;

$P_{дt}$ – хисап ае өчен t оператор мәгълүматлары буенча муниципаль берәмлекләрдә акча салынган балаларга транспортта йөрү билетлары саны;

$Д_{it}$ – хисап ае өчен t оператор мәгълүматлары буенча муниципаль берәмлекләрдә шәһәр һәм шәһәр яны элемтәсендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары буенча i транспорт оешмаларының юл йөрүләре (транзакцияләре) саныннан шәһәр һәм шәһәр яны элемтәсендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларында i транспорт оешмаларының юл йөрүләре (транзакцияләре) өлеше, ул түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$Д_{it} = \frac{П_{bdit}}{П_{bdt}},$$

монда:

$П_{вдit}$ – хисап ае өчен t оператор мәгълүматлары буенча i транспорт оешмасының шәһәр һәм шәһәр яны элемтәсендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары буенча транспортта йөрү билетлары һәм балаларга транспортта йөрү билетлары буенча юл йөрүләре (транзакцияләре) саны;

$П_{вдt}$ – хисап ае өчен t оператор мәгълүматлары буенча муниципаль берәмлекләрдә i транспорт оешмаларының шәһәр һәм шәһәр яны элемтәсендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларында транспортта йөрү билетлары һәм балаларга транспортта йөрү билетлары буенча юл йөрүләре (транзакцияләре) саны.

Транспортта йөрү билетларына һәм балаларга транспортта йөрү билетларына акча салудан, транспортта йөрү билетларын һәм балаларга транспортта йөрү билетларын сату һәм аларга акча салу пунктларыннан алынган акча t операторның исәп-хисап счетына керә һәм i транспорт оешмасы маршрутларында транспортта йөрү билетлары һәм балаларга транспортта йөрү билетлары транзакцияләре саны турындагы t оператор мәгълүматлары нигезендә транспорт оешмалары арасында бүленә. Операторларның исәп-хисап счетларына кергән акча (50 процентка кадәр), агымдагы айга транспортта йөрү билетларына һәм балаларга транспортта йөрү билетларына акча салу тәмамланган вакыттан алып өч эш көненнән дә соңга калмыйча, шәһәр һәм шәһәр яны элемтәсендә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы транспорт оешмалары арасында алдагы хисап аена i транспорт оешмасы тарафыннан күчерелгән акча күләменә пропорциональ рәвештә бүленә.

Т-оператор тарафыннан транспортта йөрү билетларына һәм балаларга транспортта йөрү билетларына акча салудан алынган акча шәһәр һәм шәһәр яны элемтәсендә җайга салына торган һәм (яки) җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы транспорт оешмалары арасында бүленгән көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча, t оператор хисап ае өчен түбәндәге мәгълүматны ирекле формада Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларына җибәрә:

акча салынган транспортта йөрү билетлары һәм балаларга транспортта йөрү билетлары саны турында;

шәһәр һәм шәһәр яны элемтәсендә i транспорт төрендә җайга салына торган һәм (яки) җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларында транспортта йөрү билетлары һәм балаларга транспортта йөрү билетлары буенча юл йөрүләр саны;

җайга салына торган һәм (яки) җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларында транспортта йөрү билеты һәм балаларга транспортта йөрү билеты буенча үтелгән пассажир-километр саны турында;

җайга салына торган һәм (яки) җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә, транспорт оешмаларына транспортта йөрү

билетларына һәм балаларга транспортта йөрү билетларына акча салудан бирелергә тиешле акча (транспорт оешмасының табышы) турында;

җайга салына торган һәм (яки) җайга салынмый торган тарифлар буенча шәһәр һәм шәһәр яны элемтәсендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары буенча транспорт оешмаларының гомуми юл йөрүләре күләменнән җайга салына торган һәм (яки) җайга салынмый торган тарифлар буенча шәһәр һәм шәһәр яны элемтәсендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутларында транспорт оешмаларының юл йөрүләре өлеше.».